СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«СТАРОИШТЕРЯКСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ИСКЕ ИШТЕРӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2025 елның 25 ноябре Иске Иштерәк ав. №9

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Иштерәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 15 октябрендәге 8/2/4-2020 номерлы карарына (07.11.2023 №41/55/4-2023, 06.06.2024 № 12/66/4-2024, 08.07.2025 №17/89/4-2025 үзгәрешләр белән) үзгәреш кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Иштерәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән, гражданнарның аерым категорияләренә җир салымы буенча бирелә торган ташламаларны Россия Федерациясе Салым кодексы нормаларына туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Иштерәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Иштерәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 15 октябрендәге 8/2/4-2020 номерлы карарына (07.11.2023 № 41/55/4-2023, 06.06.2024 № 12/66/4-2024, 08.07.2025 № 17/89/4-2025 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3 пунктның дүртенче абзацын төшереп калдырырга.

2.Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Татарстан Республикасы, Лениногорск районы Иске Иштирәк авылы Мәктәп ур., 15 йорт; Ялтау авылында Тынычлык ур., 27 йорт; Бәкер авылында, Таулы ур., 38 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru)бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Иске Иштерәк авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы
Совет рәисе

Г.Р.Шәрәпова